**Татарстан РеспубликасыТүбән Кама муниципаль районы Елантау авыл җирлеге составына керүче Елантау торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

2019елның 8 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2018 елның 16 ноябрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районының Елантау авыл җирлеге Елантау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән,1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, анда катнашучылар һәм инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәре, балачактан инвалидлар, 16 яшькә кадәр инвалид бала ата-аналары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, чакырылыш буенча хәрби хезмәттә булган солдатлардан тыш, 2019 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме. 18 яшькә кадәр өч һәм аннан да күбрәк баласы булган, 18 яшькә кадәр балаларның ялгыз аналары, мәшгульлек үзәгендә исәптә торучы гражданнар, сугышчы-интернационалистлар һәм "кайнар нокталар" да чакырылыш буенча хәрби хезмәт үткәннәр, хезмәт ветераннары билгеләнгән суммадан 50 % күләмендә түлиләр. Һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлтү:
- Набережная урамы буенча юл ремонтлау

ӘЙЕ ЮК».

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 506 җыенда катнашучы граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан җыенда катнашучы гражданнар саны 309 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 286 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 23 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Елантау авыл җирлеге составына керүче Елантау торак пунктында гражданнар җыенын булган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2.Түбән Кама муниципаль районының Елантау авыл җирлеге Елантау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән,

1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, анда катнашучылар һәм инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәре, балачактан инвалидлар, 16 яшькә кадәр инвалид бала ата-аналары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, чакырылыш буенча хәрби хезмәттә булган солдатлардан тыш, 2020 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме. 18 яшькә кадәр өч һәм аннан да күбрәк баласы булган, 18 яшькә кадәр балаларның ялгыз аналары, мәшгульлек үзәгендә исәптә торучы гражданнар, сугышчы-интернационалистлар һәм "кайнар нокталар" да чакырылыш буенча хәрби хезмәт үткәннәр, хезмәт ветераннары билгеләнгән суммадан 50 % күләмендә түлиләр. Һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлтү:

- Набережная урамы буенча юл ремонтлау

ӘЙЕ ЮК».

мәсьәләсебуенчакарар кабул ителгәндиптанырга.

3. Гражданнарҗыенынәтиҗәләренмәгълүматстендларына, ЕлантауавылҗирлегесайтындаһәмТүбән Кама муниципальрайонынынңрәсмисайтындаурнаштыру юлы беләнигъланитәргә.

4.Әлегекарарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукыйактларырегистрынакертүөченҗибәрергә.

Гражданнарҗыенындарәислекитүче
Елантауавылҗирлегебашлыгы Р. Г. Гайнетдинов